ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

“11” октябрь 2024 ел Күзкәй авылы №9

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегенең Иске Байлар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Күзкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында 2019 елның 05 ноябрендәге 10/1 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегенең Иске Байлар авылында 2024 елның 25 октябрендә 14.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Күзкәй авыл җирлегенең Иске Байлар авылы территориясендә 2025 елда балигъ булган, Күзкәй авыл җирлегенең Иске Байлар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә, I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә, аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Иске Байлар авылында янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру, янгын сүндерү колонкасы һәм янгын сүндерү җиһсәсесатфп алу);
- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Иске Байлар авылында су челтәрен алыштыру)

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Иске Байлар авылы, Гагарина урамы, 46А йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Күзкәй авыл җирлеге Башлыгы Э.Р. Гәрәев